МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2019 г.Казань № 1012

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 10 декабрендә 5980 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 №533, 06.06.2016 №316, 28.11.2016 №668, 29.03.2017 №194, 08.06.2017 №349, 22.12.2017 №895, 07.05.2018 №351, 18.09.2018 №885, 02.04.2019 №221, 03.09.2019 №666 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.11.2019 № 1012 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба текст буенча «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчада:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык)» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

1.5 пуктның җиденче абзацында «РФ Президентының 601 номерлы указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «йә шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «2 ст. 1 п.» сүзләрен «2 статьяның 1 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Балага айлык пособие (алга таба– балага пособие) билгеләү | 63-ТРЗ номерлы законның 8 статьясындагы 7 өлеше; Нигезләмәнең ункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Нигезләмәнең 1 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | Нигезләмәнең 3.13 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне | Балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза белән кирәкле барлык документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гарызнамә җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) теркәүгә алынган көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен | Нигезләмәнең 3.13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | күрсәтү вакыты гариза белән кирәкле барлык документлар теркәүгә алынган көннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла.<br>Гражданнарның керемнәре турында белешмәләргә өстәмә рәвештә тикшерү уздыру очрагында, балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар күрсәтелгән тикшерүне уздырганнан соң кабул ителә, ләкин гариза белән кирәкле барлык документларны теркәүгә алган көннән соң 30 календарь көне узганчы.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | Нигезләмә-нең 10.4 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп (банк яки башка кредит оешмасы аша балага пособие алганда), балага айлык пособие билгеләү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентның 1 нче кушымтаоында китерелде.<br>2. Бала (балалар) тууы турында таныклык күчермәсе – бала (балалар) туу турындагы актны дәүләт теркәвенә алу Татарстан Республикасыннан читтә гамәлгә ашырылган очракларда;<br>3. Гариза тапшыру алдыннан килгән алты календарь ае өчен гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары алган керемнәр турында (белешмәләре Россия Федерациясе Пенсия фондында булган түләүләрдән һәм Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсияләрдән тыш) документлар, шул исәптән:<br>а) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы | Нигезләмә-нең 3.6, 3.7, 3.8, 3.9, 3.10 пунктлары; Тәртипнең 2.1 пункты |

карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барча түләүләр турында;

б) хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача хезмәт хакы;

в) дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация;

г) эштән куылганда түләнә торган ял пособиесе, отставкага киткәндә компенсация, оешма ликвидацияләнүгә, хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән куылганда хезмәткә урнашу чорына саклана торган хезмәт хакы;

д) эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьянлык (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр;

е) отставкага киткән судьяларны ай саен гомер буе тәэмин итү;

ж) хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән өстәмә түләүләр һәм азык-төлек тәэминаты;

з) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләргә түләү;

и) социаль түләүләр:

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында

укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның дини белем бирү оешмаларында укучы дикторантларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм;

хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм 3 яшенә җиткәнче бала карау ялында булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесе бәяләмәсе буенча аларның балалары читләр каравына мохтаҗ булса, ир белән хатынның хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда айлык пособие;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләүләре;

медицина күрсәткечләре буенча академия ялында булган чорда студентларга, аспирантларга һәм докторантларга бирелә торган компенсация түләүләре;

хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә

һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре балаларына айлык пособие;

хәрби хезмәткәр яки хәрби җыеннарга чакыртылган гражданин үзенең хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) йә хәрби травма алу нәтиҗәсендә вафат булган очракта гаиләнең һәр гаилә әгъзасына түләнә торган айлык акчалата компенсация;

к) милекчелек хокукында гаиләнеке (андагы аерым әгъзаларныкы) булган мөлкәттән алынган керемнәр, андыйларга түбәндәгеләр керә:

күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гаражларны), транспорт һәм бүтән механика чараларын, продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (наемга) бирүдән алынган керемнәр;

шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җиләк-җимешләрне һәм продукцияне сатудан кергән керемнәр;

л) керемнәрнең башка төрләре, аларга түбәндәгеләр керә:

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарыннан, җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан эштән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие;

эш бирүчеләр тарафыннан үзләренең, шул исәптән инвалидлык яисә яше җитүгә бәйле рәвештә пенсиягә чыгу сәбәпле элеккеге, эштән киткән хезмәткәрләренә матди ярдәм;

Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турында законнары нигезендә алына торган авторлык бүләкләүләре, шул исәптән

мирас итеп алуның авторлык шартнамәләре буенча;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешма мөлкәте белән идарә итүдә катнашудан алынган башка керемнәр;

гаилә әгъзалары тарафыннан алына торган алиментлар;

банк кертемнәре буенча процентлар;

мирас ителгән һәм бүләк ителгән акчалар.

4. Уналты яшьтән олырак булган баланың (балаларның) Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмә.

5. Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән, гаилә әгъзалары милкендә булган күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре.

6. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның гаилә составына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның катлаулы формасыннан интегүче затлар кергән очракта, мондый авыру белән законнар нигезендә бергә яшәве мөмкин булмаган очракта, гаилә әгъзасында Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруның катлаулы формасы булуы турында белешмә.

7. Гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән (ирекле формада) документ(лар), түбәндәгеләрне раслый торган:

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү ризалыгы булуны;

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.

Ялгыз ана баласына айлык пособие алу өчен мөрәҗәгать иткән затлар өстәмә рәвештә ГХАТ органнарыннан баланың атасы турында белешмәләрне туу турында таныклыкка кертү нигезе турында белешмә тапшыра.

Ата-анасы алимент түләүдән читләшә торган балага айлык пособие алу өчен мөрәҗәгать иткән зат, яки алимент түләттерүе мөмкин булмаган очракларда, өстәмә рәвештә түбәндәге документларның берәрсен тапшыра:

әҗәте булган затның ирекtән мәхрүм итү, арест астында тору, мәҗбүри дәвалануда булу рәвешендә җәза үтүгә бәйле рәвештә алимент түләттерелә алмый торган затның кереме булмавы турында учреждениедән белешмә;

алимент түләүдән читләшүгә бәйле рәвештә әҗәтле затны эзләү турында Суд приставлары федераль хезмәтеннән карар;

ата-ананы җинаять кылган өчен җинаять җаваплылыгына тарту турында эчке эшләр органнарыннан белешмә.

Чакыру буенча хәрби хезмәт уза торган хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие алу өчен мөрәҗәгать итүче зат өстәмә рәвештә баланың атасын хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариаттан белешмә яки баланың атасының белем алуы турында һөнәри белем бирүче хәрби мәгариф учреждениесеннән белешмә тапшыра.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга

вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа гариза бирүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.

Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми

| | | |
|---|---|---|
| | файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында урнаштырылган | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>гаилә әгъзаларында күчемсез мөлкәт булуы турында белешмәләр (Росреестрда);<br>билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>гаилә әгъзаларында транспорт чараларының булуы турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләүләр, шулай ук | Нигезләмәнең 3.6, 3.7, 3.11, 3.12 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләүләр турында белешмәләр (халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте учреждениеләрендә);<br>пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә айлык матди тәэминатларның күләмнәре турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>физик зат файдасына эшкә яллаучы (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында (вәкаләтле органнарда);<br>Россия ЭЭМ түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр (Россия ЭЭМ);<br>Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр (Россия Оборона министрлыгында);<br>социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләме турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында);<br>йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының | |

| | | |
|---|---|---|
| | территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан айлык пособие күләме турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>социаль яклау органнары билгели һәм түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан билгеләнә һәм түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);<br>җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында белешмәләр, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды | |

| | | |
|---|---|---|
| | территориаль органнарында);<br>гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>опека (химаячелек) билгеләү турында, баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында, опекунның (химаячеләнең) баланы асраган өчен ала торган акча күләме һәм тәрбиягә алган ата-наларга тиешле бүләкләү суммалары турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>уналты яшьтән олырак булган баланың (балаларның) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмәләр (гомуми белем бирү оешмасыннан).<br>Гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә гариза бирүченең паспортының чын булуын раслау турында белешмәләр алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).<br>Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| | Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>3. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләргә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документларның (документларның күчермәләренең) тапшырылуы.<br>4. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү.<br>5. Гариза бирүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе.<br>6. Документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә гариза бирүче тарафыннан ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле затның мөрәҗәгать итүе.<br>7. Гариза бирүче яисә гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле зат гариза бирүченең яшәгән урынына карамаган Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе | Нигезләмә-нең 3.17 пункты |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>тулы булмаган һәм (яисә) ялган (төгәл булмаган) мәгълүматлы гариза һәм (яисә) документлар тапшырылуы;<br>бала тулы дәүләт тәэминатында булса, | Нигезләмә-нең 3.2, 3.17, 10.6 пункт-лары |

| | | |
|---|---|---|
| | затның балага пособие алу өчен мөрәҗәгать итүе;<br>әгәр гариза бирүче ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки аның ата-ана хокуклары чикләнгән булса, затның балага пособие алу өчен мөрәҗәгать итүе;<br>бала опекага (попечительлеккә) тапшырылган булып, опекунга (попечительгә) аны асраган өчен акчалата түләүләр бирелгән очракта, затның балага пособие алу өчен мөрәҗәгать итүе;<br>18 яшькә кадәрге бала өйләнешүгә яки эмансипациягә бәйле рәвештә тулы хокукка ия булган очракта, затның балага пособие алу өчен мөрәҗәгать итүе | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы | |

| | | |
|---|---|---|
| рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 пункты; 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән дә, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау | аша алу мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган кирәкле барлык документлар тапшырылган очракта, хезмәттәшлек итү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматларыннан җибәргән очракта | |

| | | |
|---|---|---|
| | турыдан-туры бергәләп эш итү таләп ителмәячәк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм гариза бирүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Татарстан Республикасы Электрон хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә | Нигезләмәнең 10.1 пункты; 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты; 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары»; |

| | | |
|---|---|---|
| | мөмкин, билгеләнгән тәртиптә ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затларның; Россия Федерациясе Пенсия фондында үзләренә һәм (яки) аларның гаилә әгъзаларына карата белешмәләр булмаган затларның (вакытлыча эшкә сәләтсез булуга һәм ана булуга бәйле рәвештә түләнә торган, Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондында яки халыкны социаль яклау бүлегендә белешмәләре булган түләүләрдән; халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре аша алына торган пособиеләрдән; шәхси ярдәмче хуҗалык алып барудан алынган керемнәрдән тыш); гаиләсендә тууы Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән, балалары булган яки Татарстан Республикасыннан читтә яки урта һөнәри белем алу оешмаларында яисә югары уку йортларында укый торган, 16 яшьтән 18 яшькәчә яшьтәге балалары булган гариза бирүчеләрнең; үз балаларының әтисе (әнисе) белән өйләнешеп тормаган һәм тол хатын (тол ир) яисә ялгыз ана булып тормаган гариза бирүчеләрнең гаризаларыннан тыш.<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе электрон формада бирелә | |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.»;

җиденче абзацны көчен югалткан дип танырга;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.1 пунктта:

дүртенче абзацта «Россия Федерациясе Пенсия фондында белешмәләре булмаган» сүзләреннән соң «(вакытлыча эшкә сәләтсез булуга һәм ана булуга бәйле рәвештә түләнә торган, Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондында яки халыкны социаль яклау бүлегендә белешмәләре булган түләүләрдән; халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре аша алына торган пособиеләрдән; шәхси ярдәмче хуҗалык алып барудан алынган керемнәрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.7 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.1 пунктның өченче абзацында «әлеге Регламентның 2.9 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлекнең 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«(дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «гариза бирүченең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«(баланың тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «баланың тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«(гариза бирүченең тулы имзасы)» сүзләреннән соң «, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулысынча)» сүзләрен өстәргә;

«(гариза бирүченең имзасы)» сүзләреннән соң «, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулысынча)» сүзләрен өстәргә;

3 нче кушымтада:

«алучының тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләрен «алучының тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«алучының адресы» сүзләрен «Гариза бирүченең адресы» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

5 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«(гариза бирүченең имзасы)» сүзләреннән соң «, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулысынча)» сүзләрен өстәргә;

кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
(белешмәлек) кушымта

Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге»
2. дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |